ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2021 г. Заинск № 432

**«Зәй муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлык) үстерү мәсьәләләре буенча Совет төзү турында»**

Зәй муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы ихтыярый берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм итү максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлык) үстерү мәсьәләләре буенча Совет булдырырга һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
2. Зәй муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлык) үстерү мәсьәләләре буенча Совет турында нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Р.Ф. Юнысова
7-52-84

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
«07» 12. 2021 ел №432
карарына 1 кушымта

**Зәй муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара советның СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Чапков Александр Владимирович | - Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, совет рәисе |
| Кашапов Айдар Җәүдәт улы | - «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары, совет рәисе урынбасары; |
| Куприянова Елена Александровна | – совет сәркатибе, яшьләр белән эшләү буенча белгеч. |
| Совет әгъзалары | |
| Камалова Регина Николаевна | - «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Сәфәргалиев Эрнст Рәис улы | - «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы; |
| Халикова Ирина Павловна | - «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы; |
| Андреева Екатерина Валерьевна | - «Зәй шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Фатыйхов Айдар Мөхәммәтнур улы | - «Зәй үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Феофанова Гөлнара Миңнулла кызы | - «ТАТМЕДИА» АҖнең «Зәй-информ» филиалы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хуҗина Эльмира Габделхак кызы | - Зәй муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
«07» 12. 2021 ел №432
карарына 2 кушымта

**Зәй муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлык) үстерү мәсьәләләре буенча совет турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлык) үстерү мәсьәләләре буенча совет - ихтыярыйлар (волонтерлар) һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге мәйданчыгы һәм ул Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә яшьләр белән эшне камилләштерүгә ярдәм итүче консультатив, мәгълүмати орган булып тора.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЭ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы законнарына һәм норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.

## 2. Советның максатлары һәм бурычлары

2.1. Совет эшчәнлегенең төп максаты - Зәй муниципаль районында ихтыярыйлык (волонтерлык) үсешенә ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге субъектларының нәтиҗәле хезмәттәшлеген оештыру.

2.2. Советның төп бурычлары:

- Зәй муниципаль районында ихтыярыйлык хәрәкәтенә (волонтерлыкка) ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары һәм ихтыярыйлар хәрәкәте (волонтерлык) эшчәнлеген координацияләү;
- Зәй муниципаль районында ихтыярыйлар хәрәкәтенә (волонтерлыкка) һәм аны үстерү буенча чараларны эшләү һәм тормышка ашыруда җирле үзидарә органнарына ярдәм итү;
- Зәй муниципаль районында ихтыярыйлар хәрәкәтенә (волонтерлыкка) ярдәм итү һәм аны үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыру өлешендә муниципаль программаларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- Зәй муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү һәм аңа ярдәм итү мәсьәләләрен карау.

## 3. Советның вәкаләтләре

Үз компетенциясе чикләрендә Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1. Совет компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

3.2. Совет әгъзаларының берсе җитәкчелегендә, Советның бурычларын һәм функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне хәл итү өчен, Совет әгъзалары арасыннан вакытлы һәм даими эшләүче эшче төркемнәр төзергә.

## 4. Советның составы

4.1. Совет совет рәисе, совет рәисе урынбасары, совет секретаре һәм совет әгъзалары составында төзелә.

4.2. Советның персональ составы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

## 5. Совет эшчәнлеген оештыру

5.1. Совет белән совет рәисе җитәкчелек итә. Совет рәисе кушуы буенча совет рәисе функцияләрен үтәү совет рәисе урынбасарына йөкләнергә мөмкин.

5.2. Совет рәисе:

- советның киләсе елга эш планын раслый;
- совет утырышының йомгаклау документын кергән көннән өч эш көне эчендә раслый.

5.3. Совет секретаре:

- совет утырышлары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары проектларын, советның башка документларын әзерләүне тәэмин итә;
- совет әгъзаларының һәм чакырылган затларның совет утырышларында катнашуын тәэмин итә;
- совет утырышларында беркетмәне алып бара һәм нәтиҗәләр буенча йомгаклау документларына кул куя, карарлар кабул иткәндә тавышларны санауны гамәлгә ашыра.

5.4. Совет утырышлары кирәк булган саен, ләкин кварталга кимендә бер мәртәбә үткәрелә.

5.5. Совет утырышында аның әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы була.

5.6. Совет рәисе яисә аның урынбасары карары буенча совет утырышы ачык яисә читтән торып тавыш бирү юлы белән үткәрелә.

Ачык тавыш биргәндә, совет әгъзаларына булачак утырыш турында хәбәр итү электрон почта, факсимиль яки телефон элемтәсе ярдәмендә совет секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Совет әгъзалары совет утырышларында шәхсән катнаша. Совет утырышында шәхсән катнашу мөмкин булмаган очракта, совет әгъзасы совет утырышын үткәрү датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча совет секретаренә хәбәр итәргә тиеш.

Совет карарлары совет утырышында катнашучыларның яисә аларның вәкилләренең гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Читтән торып тавыш биргәндә совет карарлары визаланган кәгазьләрне электрон почта, факсимиль элемтә аша килештерү юлы белән кабул ителә.

Совет әгъзалары советның йомгаклау документлары проектларын карый һәм совет секретаренә советның йомгаклау документлары проектларын килештерү турында хат юллый.

Читтән торып тавыш биргәндә совет карарлары тавыш бирүдә катнашучы совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге тавышы белән кабул ителә.

Совет карарлары йомгаклау документлары белән рәсмиләштерелә, алар өч эш көне дәвамында совет рәисе яки аның урынбасары, совет утырышында рәислек итүче, совет секретаре тарафыннан имзаланалар.

Советның йомгаклау документларын теркәү һәм аларны күрсәтелгән вазыйфаи затларга, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга җибәрү аларны имзалаганнан соң өч эш көне эчендә совет секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.7. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм мәгълүмати тәэмин итүне Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының яшьләр эшләре идарәсе башкара.